ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛЫ
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР КАРАР

2022 елның 15 декабре №2

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авылы җирлегенең Енабердино авылында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Енабердино авылы җирлегенең Енабердино авылында яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә, белем алуның көндезге формасы студентлары, вакытлы хәрби хезмәт хезмәткәрләре һәм контракт буенча хезмәт үтүче хезмәткәрләреннән тыш, I һәм II төркем инвалидлары өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләрне киметергә һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) тыл хезмәтчәннәренә һәм сугыш балаларына һәйкәл кую, территорияне төзекләндерү;

2) юлларны кардан чистарту;

3) тирәнтен насослар сатып алу;

4) Енабердино авылында Яңа урамга - 30 м. урамына һәм Мәктәп урамы - 370 м. вак таш салу өчен вак таш сатып алу

3. Енабердино авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыенының карарын игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ruhttp://www.mendeleevsk.tatar.ru/ «Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Н.Никифоров